ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Менделеевск муниципаль районы составына керүче «Менделеевск шәһәре», «Бәзәкә авыл җирлеге», «Енабердино авыл җирлеге», «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш), № 3 (I өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә:

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 137-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына

1 нче кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр чикләренең карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Менделеевск муниципаль районы чиге
-муниципаль берәмлекләр чикләре
-А-Б - Тихоново авыл жирлегенең һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г - Енабердино авыл жирлегенең һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Бәзәкә авыл жирлегенең һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- жирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар

- Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелә торган Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл жирлеге территориясе

- Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелә торган Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл жирлеге территориясе

- Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелә торган Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл жирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

1-17 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 32 (17) - 12 (18) | - Удмурт Республикасы |
| 12 (18) - 14 (66) | - Әгерҗе муниципаль районы |
| 14 (66) - 25 (64) | - Тукай муниципаль районы |
| 25 (64) - 32 (17) | - Алабуга муниципаль районы |

«Менделеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Менделеевск шәһәре |
| 2 | Абалач авыл җирлеге |
| 3 | Бәзәкә авыл җирлеге |
| 4 | Бөрешле авыл җирлеге |
| 5 | Енабердино авыл җирлеге |
| 6 | Ижевка авыл җирлеге |
| 7 | Камай авыл җирлеге |
| 8 | Монашево авыл җирлеге |
| 9 | Монай авыл җирлеге |
| 10 | Песәй авыл җирлеге |
| 11 | Иске Гришкино авыл җирлеге |
| 12 | Татар Чаллысы авыл җирлеге |
| 13 | Тихоново авыл җирлеге |
| 14 | Тойгуҗа авыл җирлеге |
| 15 | Турай авыл җирлеге |

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Менделеевск муниципаль районы Удмурт Республикасы, Алабуга, Тукай һәм Әгерҗе муниципаль районнары белән чиктәш.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Менделеевск, Алабуга муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 4,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче (17 нче) тоташу ноктасыннан алып Менделеевск, Алабуга муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тагай авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр һәм Менделеевск, Алабуга муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тагай авылыннан 3,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Менделеевск, Әгерҗе муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Ижевка авылыннан 3,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче (18 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 32 нче (17 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, аны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм көньяк-көнчыгышка таба 250 м, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 300 м, урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, 900 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, көньяк-көнчыгышка таба 20 м чокыр буенча һәм 20 м урман полосасы буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм урман полосасын кисеп үтеп, 150 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буенча бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм 1,3 км көнчыгышка таба бара, 300 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 950 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, 700 м көнчыгышка таба уза, алга таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап бара, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км, агач-куак үсемлекләре массивын һәм урман полосасын кисеп үтеп, 250 м урман полосасы буенча һәм 200 м әлеге урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Алабуга – Гәр – Абалач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп

баручы инешкә кадәр, 30 нчы тоташу ноктасына кадәр, шулай ук 29 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, «Алабуга – Гәр – Абалач» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, алга таба 200 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, 400 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Чаллы елгасына кадәр уза, 2,0 км әлеге елга агымы буенча аска таба бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Чаллы елгасының яр буе агач-куак массивын, текә ярлы участокларын һәм инешне кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба көнчыгышка таба 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Куйбышев тимер юлының илтүче тармагын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 500 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба Чаллы елгасына кадәр уза, 50 м әлеге елга агымы буенча аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярлы участокларны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 350 м көньякка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 600 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба, Алабуга – Ижевка федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк чиге буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 350 м көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне, яр буе агач-куак полосаларын һәм урман полосаларын берничә тапкыр кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, сынык сызык ясап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивының көньяк чиге буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 100 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, сынык сызык ясап, 300 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба Туйма елгасына кадәр бара, 1,4 км әлеге елга агымы буенча өскә таба, 10 м төньяк-көнчыгышка таба Туйма елгасы буенча аның сул ярына кадәр уза, агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын һәм елганың текә ярлы участогын кисеп үтә, алга таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнбатышка таба, канауны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 200 м төньяк-көнбатышка таба чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м төньякка таба карьерның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 40 м көньяк-көнбатышка таба чокырның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 40 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 300 м төньяк-көнчыгышка таба чокырның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м төньяк-

көнбатышка таба карьерның көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м урман массивы буенча, Куйбышев тимер юлы тармакларын кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Куйбышев тимер юлы тармакларын кисеп үтеп, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м профильле автомобиль юлы буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м кабат урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 450 м көнбатышка таба, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, канауны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнбатышка таба, урман полосасын, текә сул ярны һәм яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, Туйма елгасының сул ярына кадәр бара, 1,5 км әлеге елганың сул яры буенча аның агымы буенча аска таба уза, алга таба 20 м көньяк-көнбатышка таба Туйма елгасы буенча бара, 9,6 км әлеге елга агымы буенча аска таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 750 м «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлы буйлап, 1,1 км «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м профильле автомобиль юлы буйлап, сынык сызык ясап, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең төньяк чиге буйлап, 2,5 км төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м профильле автомобиль юлы буйлап, 700 м «Түбән Кама» милли паркы» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 350 м төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча Менделеевск, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Тихоново авылыннан 4,6 км көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 25 нче (64 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 25 нче (64 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 35,8 км төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча Менделеевск, Тукай һәм Әгерҗе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Ижевка авылыннан 700 м көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 14 нче (66 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 12 нче (18 нче) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча 350 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 4,2 км көньяк-көнбатышка таба 14 нче (66 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша

кишәрлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Менделеевск муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Кокшан авылыннан 1,0 км төньякта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 3 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Бәзәкә, Енабердино, Монай, Тихоново авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы белән чиктәш.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Тихоново авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Тихоново һәм Монай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Чаллысы авылыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта Туйма елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м агач-куак массивы буйлап, 150 м карьерның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м карьерның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, карьерны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, яр буендагы урман полосасын һәм «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 56 нчы урман

кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычының яр сызыгы буенча һәм 300 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагыч акваториясе буенча «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Тихоново авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=484338,14, Y=2317134,39 координаталы 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Монай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Монай һәм Енабердино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м көньякка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, дамбаларны һәм Монай авылына илтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м сәнәгать объекты буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, 50 м текә ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м текә яр буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м текә ярның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м Туйма елгасына кадәр, аның текә уң ярын кисеп үтеп, 150 м әлеге елга агымы буенча аска таба бара, аннары, Туйма елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 4,0 км әлеге елга агымы буенча аска таба 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Енабердино һәм Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карманково авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 400 м аның агымы буенча аска таба Туйма елгасына кадәр бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба әлеге елга агымы буенча, аны кисеп үтеп, 100 м Туйма елгасының уң яры буенча бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м көнбатышка таба, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньякка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары күмәк бакчалар буйлап 550 м төньякка таба һәм 200 м көнбатышка таба бара, шуннан соң 800 м төньякка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньякка таба, 250 м көнбатышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба Менделеевск шәһәренә илтүче юлга кадәр, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Бәзәкә авыл җирлеге

белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Бәзәкә авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бәзәкә авылыннан 6,7 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=484667,24, Y=2322637,26 координаталы 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 4,3 км төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап яр сызыгына кадәр уза, аннары 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагычның уң яры буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 45 нче урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м урман утыртмаларының көньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап, 350 м урман полосасы буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, һәм 400 м төньяк-көнбатышка таба юл буендагы урман полосасына кадәр бара, 400 м көньяк-көнбатышка таба аның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, урман полосасын, «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлына, профильле автомобиль юлларына һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары 150 м төньякка таба аның көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньякка таба, сынык сызык ясап, ике тапкыр кибеп баручы инешне һәм Куйбышев тимер юлы тармагын кисеп үтеп, 650 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, канауны, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба карьерга кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м карьерның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль<br>берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында» Татарстан<br>Республикасы Законына 4 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы»

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Абалач авыл җирлеге Бөрешле авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Абалач авыл җирлеге чиге Бөрешле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Абалач, Бөрешле авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 1,6 км көньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба инешкә кадәр уза, 200 м аның агымы буенча аска таба Юраш елгасына койган җиргә кадәр бара, 700 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Гәр – Абалач» – Бөрешле автомобиль юлына кадәр бара, аннары 200 м көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 100 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 2,3 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 250 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 1,6 км төньякка таба бара, сынык сызык ясап, 100 м чокыр буенча уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньякка таба, 250 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 400 м төньякка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньякка таба, 650 м көнбатышка таба, 50 м төньякка таба чокырның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, 100 м төньяк-көнчыгышка таба чокырның әлеге чиге буйлап уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Абалач, Бөрешле авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 6,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Абалач авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Абалач авыл җирлеге, Удмурт Республикасы һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тагай авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Абалач авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 5 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бәзәкә авыл җирлеге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Енабердино, Песәй, Турай авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы белән чиктәш.

Бәзәкә авыл җирлеге чиге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Бәзәкә авыл җирлеге, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бәзәкә авылыннан 6,7 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=484667,24, Y=2322637,26 координаталы 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 4,3 км төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап яр сызыгына кадәр уза, аннары 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагычның уң яры буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 45 нче урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м урман утыртмаларының көньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап, 350 м урман полосасы буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, һәм 400 м төньяк-көнбатышка таба юл буе урман полосасына кадәр бара, 400 м көньяк-көнбатышка таба аның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, урман полосасын, «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлына, профильле автомобиль юлларына һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 450 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары 150 м төньякка таба аның көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньякка таба, сынык сызык ясап, ике тапкыр кибеп баручы инешне һәм Куйбышев тимер юлы тармагын кисеп үтеп, 650 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, канауны, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба карьерга кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м карьерның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

Бәзәкә авыл җирлеге, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Енабердино авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Карманково авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бәзәкә авыл җирлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, аннары 8,7 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап Бәзәкә, Енабердино һәм Песәй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мари Тәкәше авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бәзәкә авыл җирлеге чиге Песәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 30 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 600 м көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 150 м аның агымы буенча аска таба бара, шуннан соң 600 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 450 м чокыр төбе буенча, чокырны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешне, аның текә ярларын һәм чокырны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасы буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 750 м көнчыгышка таба бара, 700 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап Бәзәкә, Песәй һәм Турай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күрәз авылыннан 1,4 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бәзәкә авыл җирлеге чиге Турай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бәзәкә, Турай авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ык Тамагы авылыннан 650 м көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=489697,94, Y=2334910,27 координаталы 16 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 2,6 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча

аның уң ярына кадәр, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына һәм Бәзәкә – Ижевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 500 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бәзәкә авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 6 нчы кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бөрешле авыл җирлеге Абалач авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Бөрешле авыл җирлеге чиге Абалач авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөрешле, Абалач авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 1,6 км көньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба инешкә кадәр уза, 200 м аның агымы буенча аска таба Юраш елгасына койган җиргә кадәр бара, 700 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Гәр – Абалач» – Бөрешле автомобиль юлына кадәр бара, аннары 200 м көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 100 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 2,3 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 250 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 1,6 км төньякка таба бара, сынык сызык ясап, 100 м чокыр буенча уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньякка таба, 250 м көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 400 м төньякка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньякка таба, 650 м көнбатышка таба, 50 м төньякка таба чокырның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, 100 м төньяк-көнчыгышка таба чокырның әлеге чиге буйлап уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөрешле, Абалач авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 6,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бөрешле авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Бөрешле авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Бөрешле авылыннан 4,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче (17 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөрешле авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 32 нче (17 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 7 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Енабердино авыл җирлеге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Бәзәкә, Камай, Монай, Песәй, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Енабердино авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Енабердино, Камай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Туйма авылыннан 800 м төньяк-көнбатышта Туйма елгасында урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге

буйлап Енабердино, Песәй авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Енабердино авыл җирлеге чиге Песәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,1 км көньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, аннары 2,8 км көньяк-көнбатышка таба әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап Енабердино, Песәй һәм Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мари Тәкәше авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Енабердино авыл җирлеге чиге Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Енабердино, Бәзәкә авыл җирлекләре һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Карманково авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, аннары 8,7 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Енабердино авыл җирлеге чиге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш 18 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 400 м аның агымы буенча аска таба Туйма елгасына кадәр бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба әлеге елга агымы буенча, аны кисеп үтеп, 100 м Туйма елгасының уң яры буенча бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м көнбатышка таба, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньякка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары күмәк бакчалар буйлап 550 м төньякка таба һәм 200 м көнбатышка таба бара, шуннан соң 800 м төньякка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньякка таба, 250 м көнбатышка таба, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба Менделеевск шәһәренә илтүче юлга кадәр, Енабердино авыл җирлеге, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Монай авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Енабердино авыл җирлеге чиге Монай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м көнбатышка таба Менделеевск шәһәренә илтүче автомобиль юлы буйлап, Енабердино, Монай һәм Иске Гришкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньякта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Енабердино авыл җирлеге чиге Иске Гришкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып, Юраш елгасын кисеп үтеп, 5,0 км төньяк-көнчыгышка таба Алабуга – Ижевск автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 500 м төньякка таба, 200 м

төньяк-көнбатышка таба бара, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба уза, 450 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м, көньякка таба, сынык сызык ясап, 750 м уза, шуннан соң 20 м көньяк-көнчыгышка таба «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, сынык сызык ясап, 150 м һәм 30 м төньяк-көнчыгышка таба су тотучы валның түбәндәге сөзәк урыны буенча, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м төньякка таба су тотучы валның түбәндәге сөзәк урыны буенча уза, аннары, сынык сызык ясап, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монай автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 2,5 км төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 26 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 26 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 300 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 300 м төньякка таба 26 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 550 м 27 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м 74 нче урман

кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнчыгышка таба 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең һәм 27 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 550 м төньяк-көнбатышка таба 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Енабердино, Иске Гришкино һәм Камай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Енабердино авылыннан 1,3 км көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Енабердино авыл җирлеге чиге Камай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 4 нче тоташу ноктасыннан алып Туйма елгасының уң яры буенча, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,4 км аның агымы буенча аска таба уза, 10 м көньяк-көнчыгышка таба Туйма елгасы буенча һәм 3,3 км аның агымы буенча аска таба уза, аннары 10 м төньяк-көнбатышка таба Туйма елгасы агымы буенча, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м карьер буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 30 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 450 м карьер буенча, сынык сызык ясап, Возжайка елгасын һәм аның текә уң ярын кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, профильле автомобиль юлына һәм Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 2,0 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 50 м көнбатышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне һәм яр буендагы агач-куак массивларын кисеп үтеп, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 40 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көньяк-көнбатышка таба, 30 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 8 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Ижевка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең

территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ижевка авыл җирлеге Турай авыл җирлеге, Әгерҗе һәм Тукай муниципаль районнары белән чиктәш.

Ижевка авыл җирлеге чиге Турай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ижевка, Турай авыл җирлекләре һәм Әгерҗе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ижевка авылыннан 1,0 км көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 450 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап аның уң ярына кадәр, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң чокырның төньяк чиге буйлап 50 м көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 100 м көньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 200 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әхтиял елгасына кадәр бара, 250 м әлеге елга агымы буенча өскә таба аңа коючы кибеп баручы инеш авызына кадәр уза, шуннан соң 250 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 40 м көньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буенча уза, шуннан соң 150 м көнбатышка таба чокырның көньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап «Бәзәкә – Ижевка» – Татар Әхтиялы автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 400 м әлеге автомобиль юлы буйлап, Бәзәкә – Ижевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 40 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м көньякка таба 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 250 м һәм көньяк чиге буйлап 50 м көнчыгышка таба уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 30 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Кама сусаклагычының уң ярына кадәр уза, аннары 800 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагыч акваториясе буенча Ижевка, Турай авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Турай авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=492265,23, Y=2336540,39 координаталы 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ижевка авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Ижевка авыл җирлеге, Тукай һәм Әгерҗе муниципаль районнары чикләре тоташкан

урында Ижевка авылыннан 700 м көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 14 нче (66 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ижевка авыл җирлеге чиге Әгерҗе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 14 нче (66 нчы) тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 9 нчы кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Камай авыл җирлеге Енабердино, Монашево, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Камай авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Камай, Монашево авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Актаҗик авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Камай, Енабердино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Туйма авылыннан 800 м төньяк-көнбатышта Туйма елгасында урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Камай авыл җирлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 4 нче тоташу ноктасыннан алып Туйма елгасының уң яры буенча, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,4 км аның агымы буенча аска таба уза, 10 м көньяк-көнчыгышка таба Туйма елгасы буенча һәм 3,3 км аның агымы буенча аска таба уза, аннары 10 м төньяк-көнбатышка таба Туйма елгасы агымы буенча, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м карьер буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 30 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 450 м карьер буенча, сынык сызык ясап, Возжайка елгасын һәм аның текә уң ярын кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, профильле автомобиль юлына һәм Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 2,0 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 50 м көнбатышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне һәм яр буендагы агач-куак массивларын кисеп үтеп, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара,

аннары 40 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көньяк-көнбатышка таба, 30 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба Камай, Енабердино һәм Иске Гришкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Енабердино авылыннан 1,3 км көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Камай авыл җирлеге чиге Иске Гришкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,1 км «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 25 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба һәм, сынык сызык ясап, төньяк чиге буйлап 900 м көнбатышка таба уза, аннары 250 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 24 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 400 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны ике тапкыр кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Камай, Иске Гришкино һәм Монашево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Илнәт авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Камай авыл җирлеге чиге Монашево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 20 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 19 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м көнчыгышка таба һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба Ерыкса елгасына кадәр уза, «Алабуга – Ижевск» – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км аның агымы буенча аска таба аңа Возжайка елгасы койган җиргә кадәр бара, 1,7 км Возжайка елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң, Возжайка елгасының текә сул ярын һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман

массивы буйлап, сынык сызык ясап, 850 м 63 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м урман полосасы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 10 нчы кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Монашево авыл җирлеге Камай, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Монашево авыл җирлеге чиге Иске Гришкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Монашево, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Илнәт авылыннан 3,6 км көньякта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Монашево, Иске Гришкино һәм Камай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Илнәт авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монашево авыл җирлеге чиге Камай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 20 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 19 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба, «Алабуга – Ижевск» – Монашево автомобиль юлына

бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба Ерыкса елгасына кадәр уза, 1,5 км аның агымы буенча аска таба аңа Возжайка елгасы койган җиргә кадәр бара, 1,7 км Возжайка елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Возжайка елгасының текә сул ярын һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман массивы буйлап, сынык сызык ясап, 850 м 63 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м урман полосасы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Монашево, Камай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Актаҗик авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Монашево авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 1 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монашево авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Монашево авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Кокшан авылыннан 1,0 км төньякта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 11 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге территориясе чигенең
картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Монай авыл җирлеге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Енабердино, Иске Гришкино, Тихоново, Татар Чаллысы авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Монай авыл җирлеге чиге Тихоново авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Монай, Тихоново авыл җирлекләре һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Татар Чаллысы авылыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта Туйма елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м Туйма елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары көньякка таба 10 м әлеге елга буенча, 100 м

агач-куак массивы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Монай, Тихоново һәм Татар Чаллысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салтыковка авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монай авыл җирлеге чиге Татар Чаллысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып, Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 7,6 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев тимер юлы тармагы буенча уза, 4,3 км «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлы буйлап бара, аннары сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм 20 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Монай, Татар Чаллысы авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Абалач авылыннан 5,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монай авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Монай, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Илкә авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта Юраш елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Монай авыл җирлеге чиге Иске Гришкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып 800 м Юраш елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 800 м кабат көньяк-көнчыгышка таба, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 850 м 44 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба 44 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң 600 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аның Монай инешенә койган җиренә кадәр уза, 350 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Алабуга – Ижевск автомобиль юлына кадәр бара, аннары 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Монай, Иске Гришкино һәм Енабердино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньякта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Монай авыл җирлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Монай һәм Енабердино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнбатышка таба Менделеевск

шәһәренә илтүче автомобиль юлы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Монай авыл җирлеге чиге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м көньякка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, дамбаларны һәм Монай авылына илтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м сәнәгать объекты буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, 50 м текә ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м текә яр буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м текә ярның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м Туйма елгасына кадәр, аның текә уң ярын кисеп үтеп, 150 м әлеге елга агымы буенча аска таба бара, аннары, Туйма елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 4,0 км әлеге елга агымы буенча аска таба 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 12 нче кушымта

## Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Песәй авыл җирлеге Бәзәкә, Енабердино, Тойгуҗа, Турай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Песәй авыл җирлеге чиге Турай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Песәй, Турай һәм Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күрәз авылыннан 1,4 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 300 м төньякка таба урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чумак елгасына кадәр бара, 650 м аның агымы буенча аска таба уза, шуннан соң, әлеге елганың текә сул ярын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман

полосасы буйлап, 2,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм 1,8 км төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 950 м әлеге инеш агымы буенча аска таба буага кадәр бара, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба буаның уң яры буйлап буага коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, 2,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба аның башына кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны, агач-куак массивын, кибеп баручы инешне һәм текә ярны кисеп үтеп, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба, текә ярларны һәм Әхтиял елгасын кисеп үтеп, 450 м кабат төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Песәй, Турай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Әхтиялы авылыннан 4,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Песәй авыл җирлеге чиге Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Песәй, Бәзәкә һәм Енабердино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мари Тәкәше авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 30 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 600 м көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 150 м аның агымы буенча аска таба бара, шуннан соң 600 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 450 м чокыр төбе буенча, чокырны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешне, аның текә ярларын һәм чокырны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасы буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 750 м көнчыгышка таба бара, 700 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап 17 нче

тоташу ноктасына кадәр уза.

Песәй авыл җирлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Песәй, Енабердино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,1 км көньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, аннары 2,8 км көньяк-көнбатышка таба әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Песәй авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Песәй, Тойгуҗа авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 1,4 км төньякта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Песәй авыл җирлеге чиге Тойгуҗа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 450 м көньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба, урман полосаларын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 5,1 км Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап аны кисеп үтеп бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, «Песәй – Кырынды» – Тойгуҗа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 250 м, 350 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кабат «Песәй – Кырынды» – Тойгуҗа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м 17 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман утыртмаларын, чокырны һәм урман полосасын кисеп үтеп, 800 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Песәй, Тойгуҗа авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Рус Сарсазы авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Песәй авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 13 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Гришкино авыл җирлеге Енабердино, Камай, Монашево, Монай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Иске Гришкино авыл җирлеге чиге Монашево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Монашево, Иске Гришкино авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Илнәт авылыннан 3,6 км көньякта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Монашево, Иске Гришкино һәм Камай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Илнәт авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Гришкино авыл җирлеге чиге Камай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Гришкино, Камай һәм Енабердино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Енабердино авылыннан 1,3 км көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,1 км «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 25 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба һәм, сынык сызык ясап, төньяк чиге буйлап 900 м көнбатышка таба уза, аннары 250 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 24 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 400 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, «Алабуга –

Ижевск» – Илнәт – Монашево автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны ике тапкыр кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Гришкино авыл җирлеге чиге Енабердино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Гришкино, Енабердино һәм Монай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 550 м төньякта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып, Юраш елгасын кисеп үтеп, 5,0 км төньяк-көнчыгышка таба Алабуга – Ижевск автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 500 м төньякка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба уза, 450 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м, көньякка таба, сынык сызык ясап, 750 м уза, шуннан соң 20 м көньяк-көнчыгышка таба «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, сынык сызык ясап, 150 м һәм 30 м төньяк-көнчыгышка таба су тотучы валның түбәндәге сөзәк урыны буенча, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м төньякка таба су тотучы валның түбәндәге сөзәк урыны буенча уза, аннары, сынык сызык ясап, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Ижевск» – Илнәт – Монай автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 2,5 км төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 26 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 26 нчы урман кварталының көньяк чиге

буйлап 300 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 300 м төньякка таба 26 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 550 м 27 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнчыгышка таба 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең һәм 27 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 550 м төньяк-көнбатышка таба 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Гришкино авыл җирлеге чиге Монай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Гришкино, Монай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Илкә авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта Юраш елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып 800 м Юраш елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 800 м кабат көньяк-көнчыгышка таба, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 850 м 44 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба 44 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң 600 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аның Монай инешенә койган җиренә кадәр уза, 350 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Алабуга – Ижевск автомобиль юлына кадәр бара, аннары 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Гришкино авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 14 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Татар Чаллысы авыл җирлеге Монай, Тихоново авыл җирлекләре, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Монай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Чаллысы, Монай һәм Тихоново авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салтыковка авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып, Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 7,6 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев тимер юлы тармагы буенча уза, 4,3 км «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлы буйлап бара, аннары сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм 20 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Татар Чаллысы, Монай авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Абалач авылыннан 5,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Тихоново авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Чаллысы, Тихоново авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Салтыковка авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Татар Чаллысы авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тагай авылыннан 3,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 15 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге территориясе чигенең
картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тихоново авыл җирлеге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Монай, Татар Чаллысы авыл җирлекләре, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары белән чиктәш.

Тихоново авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Тихоново авыл җирлеге, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Монай авылыннан 3,9 км көньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=484338,14, Y=2317134,39 координаталы 20 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Тихоново авыл җирлеге, Алабуга һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Тихоново авылыннан 4,6 км көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 25 нче (64 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Тихоново авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (64 нче) тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Тихоново, Татар Чаллысы авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Салтыковка авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тихоново авыл җирлеге чиге Татар Чаллысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тихоново, Татар Чаллысы һәм Монай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Салтыковка авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тихоново авыл җирлеге чиге Монай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тихоново, Монай авыл җирлекләре һәм «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Татар Чаллысы авылыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта Туйма елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м Туйма елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары көньякка таба 10 м әлеге елга буенча, 100 м агач-куак массивы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тихоново авыл җирлеге чиге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м агач-куак массивы буйлап, 150 м карьерның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м карьерның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, карьерны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, яр буендагы урман полосасын һәм «Мәскәү – Уфа» – Бәзәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычының яр сызыгы буенча һәм 300 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагыч акваториясе буенча 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль<br>
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль<br>
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү<br>
һәм аларның статусы турында» Татарстан<br>
Республикасы Законына 16 нчы кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан

Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тойгуҗа авыл җирлеге Песәй авыл җирлеге һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Тойгуҗа авыл җирлеге чиге Песәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тойгуҗа, Песәй авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 1,4 км төньякта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 450 м көньякка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба, урман полосаларын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 5,1 км Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап аны кисеп үтеп бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, «Песәй – Кырынды» – Тойгуҗа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 250 м, 350 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кабат «Песәй – Кырынды» – Тойгуҗа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м 17 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман утыртмаларын, чокырны һәм урман полосасын кисеп үтеп, 800 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Тойгуҗа, Песәй авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Рус Сарсазы авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Тойгуҗа авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына 17 нче кушымта

**Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Менделеевск муниципаль районы»

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Турай авыл җирлеге Бәзәкә, Ижевка, Песәй авыл җирлекләре, Әгерҗе, Тукай муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Турай авыл җирлеге чиге Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Турай, Бәзәкә авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ык Тамагы авылыннан 650 м көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=489697,94, Y=2334910,27 координаталы 16 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 2,6 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча аның уң ярына кадәр, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына һәм Бәзәкә – Ижевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 500 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Турай, Бәзәкә һәм Песәй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күрәз авылыннан 1,4 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Турай авыл җирлеге чиге Песәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 300 м төньякка таба урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чумак елгасына кадәр бара, 650 м аның агымы буенча аска таба уза, шуннан соң әлеге елганың текә сул ярын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 2,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм 1,8 км төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 950 м әлеге инеш агымы буенча аска таба буага кадәр бара, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба буаның уң яры буйлап буага коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, 2,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба аның башына кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны, агач-куак массивын, кибеп баручы инешне һәм текә ярны кисеп үтеп, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба, текә ярларны һәм Әхтиял елгасын кисеп үтеп, 450 м кабат төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Турай, Песәй авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Әхтиялы авылыннан 4,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Турай авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Турай авыл җирлеге, Удмурт Республикасы һәм Әгерҗе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ижевка авылыннан 3,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче (18 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Турай авыл җирлеге чиге Әгерҗе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 12 нче (18 нче) тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Турай, Ижевка авыл җирлекләре һәм Әгерҗе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ижевка авылыннан 1,0 км көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Турай авыл җирлеге чиге Ижевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 450 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап аның уң ярына кадәр, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң чокырның төньяк чиге буйлап 50 м көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 100 м көньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 200 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әхтиял елгасына кадәр бара, 250 м әлеге елга агымы буенча өскә таба аңа коючы кибеп баручы инеш авызына кадәр уза, шуннан соң 250 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 40 м көньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буенча уза, шуннан соң 150 м көнбатышка таба чокырның көньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап «Бәзәкә – Ижевка» – Татар Әхтиялы автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 400 м әлеге автомобиль юлы буйлап, Бәзәкә – Ижевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 40 м «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Менделеевск участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м көньякка таба 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 250 м һәм көньяк чиге буйлап 50 м көнчыгышка таба уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба 69 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 30 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Кама сусаклагычының уң ярына кадәр уза, аннары 800 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге сусаклагыч акваториясе буенча Ижевка, Турай авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Турай авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=492265,23,

Y=2336540,39 координаталы 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Турай авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.».